ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕАТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 2а, д.Нижние Аты ,
Арский муниципальный район, 422016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 2а йорт, Түбән Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422016

Тел. (84366)507-35, факс (84366)507-35 E-mail: SatArs@tatar.ru

**КАРАР**

**« 30 » сентябрь 2016 ел** **№11**

**Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Аты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирде:

1.Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

«2017 елда Урта Аты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә (түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иту гә җибәрү белән килешәсезме?

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| | Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру(урам яктырту) | Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урам яктырту) - урам утларын алыштыру һәм урнаштыру<br>Түбән Аты авылы<br>Урта Сәрдә авылы<br><br>- каты көнкүреш калдыкларын вакытлыча җыючы урыннарны карап тоту, чүп-чарны трактор белән тыгызлау; торак пунктларда | <br><br><br>5000<br><br>5000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Тубән Аты авылы<br>Урта Сәрдә авылы | 5000<br>5000 |
| 1 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларында арата юл эшчәнлеге | - Урта Аты авыл җирлеге составына керә торган юлларга вак таш салу;<br><br>ТУбән Аты Аты авылы, Кече ур., (1-31 йортлар һәм Югары урам 1-5 йорт,һәм 20-24 йортлар)<br>Урта Сәрдә авылы, Югары урам 1-20 йорт<br><br>Кылычы авылы Яшеллек урамы 1-14 йортлар | <br><br>112500<br><br>48900<br><br>18300 |
| | Җирлек чикләрендә су белән тәэмин итүне оештыру | Урта авылда су челтәрләрен ремонтлау Аты күпер ур.<br><br>Күмелгән урыннарны карап тоту урта авылда зират коймасы җайланмасы Аты | 10000 |
| | Зиратларны карау | Урта Аты авылында зират коймасы тоту | 10000 |
| | Барлыгы | | 224700 |

әйе юк

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Тубән Аты авылы, Үзәк ур., дом 37, Арча районы, Урта Аты авылы, Үзәк ур., дом 70А,

3.Әлеге карарны Урта Аты авыл җирлеге Советына җибәрергә.

Урта Аты авыл җирлеге башлыгы Мухамадиев Я.З